| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**01.02.2018** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 200** |

Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында

Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 01 октябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» гы 2220 номерлы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибен яңа редакциядә (кушымтада) бәян итәргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 01 октябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» гы 2220 номерлы карарының 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеген компенсация түләүләре өчен вәкаләтле орган итеп билгеләргә».

3. Әлеге карар 2018 елның 01 февраленнән үз көченә керә.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы

Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 01 февралендәге
200 номерлы карарына кушымта

# Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибе

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре тәртибен, билгеләү шартларын һәм түләүне билгели (алга таба - компенсация).

1.2. Компенсация законлы вәкилгә (ата - анага, уллыкка алучыга, опекунга) яки аның вәкаләтле затына, белем бирү оешмасы белән килешү төзегән һәм баланы мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы тиешле мәгариф оешмасына караган өчен ата-ана түләве керткән (алга таба-мөрәҗәгать итүче), гаиләнең җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнә һәм түләнә.

1.3. Компенсация алуга хокукны билгеләгәндә гаиләнең җан башына туры килә торган кереме «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

Компенсация билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме барлык кирәкле документлар белән компенсация билгеләү турында гариза биргән айга кадәрге соңгы алты календарь ай өчен билгеләнә (алга таба исәп - хисап чоры).

Гаиләнең җан башына уртача керемен билгеләгәндә, аерым яки бергә яшәүләренә бәйсез рәвештә, компенсация алучының ире (хатыны) булган гражданнарның керемнәре исәпкә алына.

Исәп-хисап чорында гаиләнең җан башына уртача кереме уртача айлык җыелма керемне гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләнә.

Исәп-хисап чорында гаиләнең уртача айлык җыелма кереме гаиләнең барлык әгъзаларының уртача айлык керемнәре суммасына тигез.

Гаиләнең һәр әгъзасының уртача айлык кереме аның хисап чоры дәвамында алынган керемнәре суммасын әлеге хисап чорындагы айлар санына бүлү юлы белән билгеләнә.

1.4. Гаилә составында компенсация күләмен билгеләгәндә түбәндәгеләр исәпкә алына:

иждивениедә булган һәм 18 яшькә җитмәгән , шул исәптән хастаханәләрдә, балалар шифаханәләрендә дәвалануда булган балалар, шулай ук интернат мәктәпләрдә матди карап тору өчен ата-аналары өлешчә түләү кертә торган балалар;

көндезге формада, шул исәптән дәүләтнеке булмаган уку учреждениеләрендә белем алучы , ата-аналары белән уртак яшәү фактына карамастан, 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге (никахта тормаган) балалар;

гаиләдә яшәүче үги малайлар һәм үги кызлар, әгәр алар башка ата-ана гаиләсендә исәпкә алынмаса;

гражданнар гаиләләрендә опекада торучы балалар;

тәрбиягә бала алучы гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар.

1.5. Гаилә составына түбәндәге балалар исәпкә алынмый:

-аларга карата ике ата-анасы да (бер ата-ана - тулы булмаган гаиләдә) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән;

-тулысынча дәүләт тәэмин итүендә булганнар.

1.6. Компенсация күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

ДК= Ф х (100-МДД) - К, биредә

ДК – компенсация күләме;

Ф - мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен фактта кертелгән ата-аналар түләве күләме, тиешле елга Башкарма комитет карары белән расланган ата-ана түләве күләме чикләрендә;

МДД - мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләве буенча гражданнар чыгымнарының таблица нигезендә билгеләнә торган мөмкин булган максималь өлеше

К - «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 январендаге 9 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешен компенсацияләү күләме

Таблица

Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенә гражданнарның максималь рөхсәт ителгән чыгымнары өлеше

| Гаиләнең бер әгъзасына керем күләме | Ата-ана түләвенә гражданнарның максималь рөхсәт ителгән чыгымнары өлеше (%) | | |
|---|---|---|---|
| | 1 балага | 2 балага | 3 балага |
| 10 000 сумга кадәр | 60 | 38 | 23 |
| 10 001 дән 15 000 сумга кадәр | 70 | 43 | 36 |
| 15 001 дән 20 000 сумга кадәр | 80 | 53 | 53 |
| 20 000 сумнан артык | 100 | 100 | 100 |

1.5. Компенсация билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме барлык кирәкле документлар белән компенсация билгеләү турында гариза биргән айга кадәрге соңгы алты календарь ай өчен билгеләнә (алга таба исәп - хисап чоры).

## 2. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

2.1. Компенсация алу өчен мөрәҗәгать итүче яшәү урыны (тору урыны буенча мөрәҗәгать итүче яшәү урынында теркәлмәгән очракта) муниципаль районда (шәһәр округында) компенсация түләүгә вәкаләтле органга (алга таба - вәкаләтле орган) түбәндәге документларны тапшыра:

a) компенсация билгеләү турында гариза;
b) өстәмә компенсация бирү турында гариза биргән айга кадәрге алты ай эчендәге гаиләнең һәр әгъзасының керемнәре турында документлар;
c) компенсация билгеләнә торган баланың туу турында таныклык күчермәсе (әгәр күчермә нотариаль таныкланмаган булса, оригиналны күрсәтеп);
d) мөрәҗәгать итүче әнисе, әтисе (законлы вәкиле) булган башка балаларының туу (уллыкка алу) турында таныклык күчермәләре (әгәр күчермә нотариаль рәвештә расланмаган булса, оригиналны күрсәтеп) Опекадагы балага компенсация билгеләү өчен өстәмә рәвештә балага опека билгеләнүе турында җирле үзидарә органнары карарыннан өземтә тапшырыла;
e) Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычлы затлар өчен ышанычнамә күчермәсе;
f) ата-ананың берсесенә (ата-аналарга) балага (балаларга) карата ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән очракта суд карары;
g) баланы тиешле мәгариф оешмасына урнаштыру турындагы шартнамәнең күчермәсе;

h) баланы мәгариф оешмасында караган һәм тәрбияләгән өчен түләү квитанциясенең күчермәсе;
i) мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслый торган документ(документлары) (теләсә нинди формада) :
j) - үзләренең персональ мәгълүматларын эшкәртүгә риза булуын;
k) -мөрәҗәгать итүченең персональ мәгълүматны органга яки оешмага тапшырганда үз исеменнән эш итү вәкаләтен.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә , банк аша компенсация алганда,мәгариф оешмасы белән килешү төзегән затның кредит оешмасындагы шәхси счет номерын, паспортын (аны алыштыручы документны)күрсәтә.

Мөрәҗәгать иткән көнгә мөрәҗәгать итүче гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнгән социаль ярдәм чараларын алучы булса, мөрәҗәгать итүче керемнәр турында белешмәләр бирүдән азат ителә.

Мөрәҗәгать итү көнендә мөрәҗәгать итүче «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләүенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 январендәге 9 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнә торган мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алучы булса, мөрәҗәгать итүче 2.1 пунктның c)-h) пунктчасында күрсәтелгән белешмәләрне бирүдән азат ителә.

Мәҗбүри социаль иминиятләштерелмәгән (эшләмәгән) һәм 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге баланы карау ялында булган мөрәҗәгать итүчеләр өчен эшсезлек чорын җитди сәбәп дип санарга һәм мәктәпкәчә балалар оешмаларында мәгариф оешмаларына йөрүче балаларга өстәмә компенсация исәпләгәндә "нульле керем" исәпкә алырга.

2.2. Гариза һәм документлар почта аша җибәрелергә мөмкин. Гаризаны һәм документларны почта аша җибәрү вәкаләтле орган тарафыннан алу фактын һәм датасын расларга мөмкинлек бирә торган ысул белән гамәлгә ашырыла.

2.3. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә вәкаләтле орган гаризаны теркәгән көннән алып 10 көн эчендә барлык кирәкле документлар белән компенсация билгеләү яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (хат, смс-хәбәр, электрон почта аша ,ә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан теркәлгән кулланучы-мөрәҗәгать итүчеләр өчен - шәхси кабинет аша хәбәрнамә белән) мөрәҗәгать итүчегә тиешле карарны җиткерә .

2.4. Компенсация билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

әлеге тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

гамәлдә булу срогы чыккан документларны тапшыру (күрсәтү) ;

законнар таләпләрен бозып тутырылган документларны тапшыру.

2.5. Компенсация барлык кирәкле документлар белән гариза биргән айдан билгеләнә һәм 6 ай дәвамында түләнә.

2.6. Гражданнар тарафыннан торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә алдан билгеләнгән субсидия яки балага айлык пособие алынган очракта, граждан гаризасы буенча компенсация субсидия бирү срогы яисә балага айлык пособие бирү срогы тәмамланганчыга кадәр билгеләнергә мөмкин.

Әгәр компенсация алучы торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия яки айлык балалар пособиесе билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән гражданның гаиләсе составына керә икән,элек билгеләнгән компенсация, алучының гаризасы буенча, субсидия яисә айлык пособие алучы биргән документларны исәпкә алып, балага субсидия яисә айлык пособие алу чорына яңадан билгеләнергә мөмкин.

2.7. Махсуслаштырылган оешмага Россия Федерациясе Пенсия фондыннан алырга мөмкинлек бирә торган мәгълүмати бәйләнеш кертелгәннән соң, шул исәптән ведомствоара электрон бәйләнешләрнең бердәм системасын һәм аңа тоташа торган ведомствоара мәгълүмати бәйләнешләрнең региональ системаларын кулланып, эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка бүләкләр суммасы турында белешмә компенсация билгеләү гаризада күрсәтелгән ризалыгы нигезендә, мөрәҗәгать итүченең компенсация билгеләүгә мөрәҗәгать иткән аена кадәрге 12 айның соңгы 6 аенда Россия Федерациясе Пенсия фондында булган мәгълүматлар нигезендә башкарыла.

2.8. Үзәк бүлекчәсендә гражданның компенсациягә хокукын раслый торган белешмәләр булганда, компенсация аңа яңа срокка автомат рәвештә, гражданның мөрәҗәгатеннән башка билгеләнә.

## 3. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Мөрәҗәгать итүче тапшырылган мбелешмәләрнең дөреслеге, шулай ук аларны үз эченә алган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.2. Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган документларның чынлыгына һәм дөреслегенә шик туган очракта, мөрәҗәгать итүче биргән вәкаләтләр кысаларында, өстәмә тикшерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

3.3. Компенсация суммасы мөрәҗәгать итүченең банк счетына күчерелә.

Сәламәтлеге торышы буенча мөмкинлекләре булмаган мөрәҗәгать итүчегә, яше, җәяү барып яисә транспортта банк счетын ачарга һәм алардан файдалана алмау аркасында, компенсация түләү (китерү) элемтә оешмасы аша яисә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән башка оешмалар акчалата түләүләрне китереп торучы башка оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

3.4. Банк счетларына күчерү һәм почта элемтәсе белән илтеп җиткерү яки гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән оешмалар тарафыннан акчалата түләүләрне китерүне

гамәлгә ашыручы башка оешмалар компенсацияне исәп-хисап ае дәвамында башкарыла.

3.5. Гражданнар вәкаләтле органга билгеләнгән компенсация түләүне туктатуга китерә торган шартлар барлыкка килү турында (белем бирү оешмасын алыштыру, ата-ана хокукларын чикләү, мөрәҗәгать итүченең үлеме) мондый хәлләр башланганнан соң бер айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Түләүне туктатуга китергән шартлар барлыкка килгәндә, түләү тиешле шартлар килеп чыккан айдан соң киләсе айдан туктатыла.

3.7. Дөрес булмаган мәгълүматлар булган документлар тапшыру, өстәмә компенсация алу хокукына йогынты ясый торган мәгълүматларны яшерү нәтиҗәсендә артык түләнгән компенсация суммалары мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләтле органны казна счетына кертү юлы белән үз теләге белән каплана, ә мөрәҗәгать итүче баш тарткан очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә түләтелә.

3.8. Вәкаләтле орган гаебе белән вакытында түләнмәгән компенсация суммасы үткән вакыт өчен срогы чикләнмичә түләнә.

3.9. Мөрәҗәгать итүче вафат булган очракта, аңа исән чакта түләнмәгән компенсация суммалары мирас составына кертелә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләрдә мирас итеп алына.

3.10. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.